**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**Вопросы Управления записи актов гражданского состояния Кабинета Министров Республики Татарстан**

В соответствии с Федеральным законом от 15 ноября 1997 года № 143-ФЗ «Об актах гражданского состояния», Законом Республики Татарстан от 30 декабря 2005 года № 146-ЗРТ «О наделении органов местного самоуправления в Республике Татарстан полномочиями на государственную регистрацию актов гражданского состояния», а также руководствуясь статьей 94 Конституции Республики Татарстан и Законом Республики Татарстан от 6 апреля 2005 года № 64-ЗРТ «Об исполнительных органах государственной власти Республики Татарстан», **постановляю**:

1. Уполномочить Управление записи актов гражданского состояния Кабинета Министров Республики Татарстан на:

осуществление организации деятельности по государственной регистрации актов гражданского состояния и ее методического и консультационного обеспечения;

установление требований к содержанию и формам отчетности органов местного самоуправления муниципальных образований Республики Татарстан об осуществлении переданных им полномочий на государственную регистрацию актов гражданского состояния, а также к порядку представления такой отчетности;

установление порядка ежемесячного представления органами местного самоуправления муниципальных районов и городских округов сведений, связанных с государственной регистрацией актов гражданского состояния, в Управление записи актов гражданского состояния Кабинета Министров Республики Татарстан;

установление порядка и сроков представления органами местного самоуправления городских и сельских поселений, входящих в состав муниципальных районов, записей актов гражданского состояния на бумажных носителях, а также сведений, связанных с государственной регистрацией актов гражданского состояния, в органы местного самоуправления муниципальных районов;

осуществление в пределах своей компетенции контроля за надлежащим осуществлением органами местного самоуправления муниципальных

образований Республики Татарстан переданных им полномочий на государственную регистрацию актов гражданского состояния, соблюдением требований законодательства об актах гражданского состояния, а также прав и законных интересов граждан при регистрации актов гражданского состояния.

2. Утвердить прилагаемую структуру Управления записи актов гражданского состояния Кабинета Министров Республики Татарстан.

3. Управлению записи актов гражданского состояния Кабинета Министров Республики Татарстан осуществлять своевременное представление в федеральный орган исполнительной власти, осуществляющий функции по выработке и реализации государственной политики и нормативно-правовому регулированию, а также контролю и надзору в сфере государственной регистрации актов гражданского состояния, экземпляров нормативных правовых актов, принимаемых органами государственной власти Республики Татарстан по вопросам переданных полномочий на государственную регистрацию актов гражданского состояния, а также отчетности об осуществлении указанных полномочий.

4. Министерству финансов Республики Татарстан осуществлять своевременное представление в федеральный орган исполнительной власти, осуществляющий функции по выработке государственной политики и нормативно-правовому регулированию в сфере бюджетной, налоговой, страховой, валютной, банковской деятельности, а также в уполномоченный федеральный орган исполнительной власти, осуществляющий функции по контролю и надзору в сфере государственной регистрации актов гражданского состояния, отчета о расходовании субвенций, предоставленных на реализацию переданных полномочий на государственную регистрацию актов гражданского состояния.

5. Установить, что полномочия, предусмотренные пунктом 1 настоящего Указа, осуществляются Управлением записи актов гражданского состояния Кабинета Министров Республики Татарстан в пределах установленной предельной численности его работников и фонда оплаты труда.

6. Кабинету Министров Республики Татарстан привести свои акты в соответствие с настоящим Указом, а также принять иные решения, обеспечивающие его реализацию.

7. Признать утратившим силу Указ Президента Республики Татарстан от 11 марта 2009 года № УП-141 «Вопросы Управления записи актов гражданского состояния Кабинета Министров Республики Татарстан».

8. Настоящий Указ вступает в силу со дня его подписания.

**Президент**
**Республики Татарстан** **Р.Н. Минниханов**

Казань, Кремль
25 декабря 2020 года
№ УП-876

Утверждена
Указом Президента
Республики Татарстан

от «25» декабря 2020 года

№ УП-876

**Структура**
**Управления записи актов гражданского состояния Кабинета Министров Республики Татарстан**




_______________

**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Гражданлык хәле актларын теркәү идарәсе мәсьәләләре**

«Гражданлык хәле актлары турында» 1997 елның 15 ноябрендәге 143-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнарына гражданлык хәле актларын дәүләт теркәвенә алу вәкаләтләре бирү турында» 2005 елның 30 декабрендәге 146-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, шулай ук Татарстан Республикасы Конституциясенең 94 статьясы һәм «Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары турында» 2005 елның 6 апрелендәге 64-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына таянып, **карар бирәм**:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Гражданлык хәле актларын теркәү идарәсенә түбәндәге вәкаләтләрне бирергә:

гражданлык хәле актларын дәүләт теркәвенә алу эшчәнлеген һәм аны методика һәм консультацияләр бирү ягыннан тәэмин итүне оештыру;

Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләр җирле үзидарә органнарының аларга тапшырылган гражданлык хәле актларын дәүләт теркәвенә алу вәкаләтләрен башкарулары турындагы хисапларның эчтәлегенә һәм формасына, шулай ук әлеге хисапларны бирү тәртибенә таләпләр кую;

муниципаль районнар һәм шәһәр округлары җирле үзидарә органнарының гражданлык хәле актларын дәүләт теркәвенә алу белән бәйле белешмәләрне Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Гражданлык хәле актларын теркәү идарәсенә ай саен тапшыру тәртибен билгеләү;

муниципаль районнар составына керә торган шәһәр һәм авыл җирлекләре җирле үзидарә органнары тарафыннан гражданлык хәле актларын теркәүнең кәгазь чыганакларда, шулай ук гражданлык хәле актларын дәүләт теркәвенә алу белән бәйле мәгълүматларны муниципаль районнарның җирле үзидарә органнарына бирү тәртибен һәм вакытын билгеләү;

Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләр җирле үзидарә органнарының аларга тапшырылган гражданлык хәле актларын дәүләт теркәвенә алу вәкаләтләренең гражданлык хәле актлары турындагы законнар таләпләрен, шулай ук гражданлык хәле актларын теркәгәндә гражданнарның

хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен үтәп, үз компетенцияләре чикләрендә тиешенчә башкаруларын контрольдә тоту.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Гражданлык хәле актларын теркәү идарәсенең кушымтада бирелүче структурасын расларга.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Гражданлык хәле актларын теркәү идарәсе гражданлык хәле актларын дәүләт теркәвенә алу буенча тапшырылган вәкаләтләр, шулай ук әлеге вәкаләтләрне башкару буенча хисап тоту мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары кабул итә торган норматив хокукый актлар нөсхәләрен гражданлык хәле актларын дәүләт теркәвенә алу өлкәсендә дәүләт сәясәтен эшләү һәм гамәлгә ашыруны, шулай ук гражданлык хәле актларын дәүләт теркәвенә алу өлкәсендә контроль һәм күзәтчелек функцияләрен башкаручы федераль башкарма хакимият органына үз вакытында тапшырырга тиеш.

4. Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы бюджет, салым, иминиятләштерү, валюта, банк эшчәнлеге өлкәсендә дәүләт сәясәтен эшләү һәм норматив-хокукый җайга салу функцияләрен башкаручы федераль органга, шулай ук граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу өлкәсендә контроль һәм күзәтчелек функцияләрен башкаручы вәкаләтле федераль башкарма хакимият органына гражданлык хәле актларын дәүләт теркәвенә алу буенча тапшырылган вәкаләтләрне башкаруга бирелгән субвенцияләрне тоту турындагы хисапны тапшырырга тиеш.

5. Әлеге Указның 1 пунктында каралган вәкаләтләр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Гражданлык хәле актларын теркәү идарәсе тарафыннан аны хезмәткәрләренең билгеләнгән чик саны һәм хезмәткә түләү фонды чикләрендә башкарыла дип билгеләргә.

6. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына үз актларын әлеге Указга туры китерергә, шулай ук аны гамәлгә ашыруны тәэмин итүче башка карарлар кабул итәргә.

7. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Граждан хәле актларын теркәү идарәсе мәсьәләләре» 2009 елның 11 мартындагы ПУ-141 номерлы Указын үз көчен югалткан дип танырга.

8. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Президенты** — **Р.Н. Миңнеханов**

ГОМУМИ БҮЛЕК

Казан, Кремль
2020 ел, 25 декабрь
№ ПУ-876

Татарстан Республикасы
Президентының
2020 елның «25 » декабрендәге
ПУ- 876 номерлы Указы белән
расланды

**Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Гражданлык хәле актларын теркәү идарәсе структурасы**

